СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

19 июль, 1997ел.
ШИМБӘ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.

№ 79 (8091)

Бәясе билгеләнгәнчә

## ИЛГӘ МУЛЛЫК БИРГӘН ХЕЗМӘТЕГЕЗ ҮЗЕГЕЗГӘ ХӨРМӘТ КИТЕРӘ

## Бүген - савымчылар җыены

Елның һәр туар көнен авылдагы һәркемнән дә иртә башлаучы, йокының иң тәмле вакытында фермага ашыгучы сыер савучыларыбызга да бер генә көнгә булса да иркенләп ял итү, күңел ачу, нәкъ алар өчен генә әзерләнгән нигъмәт тулы өстәлләр артында барысы бергә җыелышып утырып чәй эчү, ел буе күрмәгән күптәнге танышлары белән очрашып чүкердәшү мөмкинлеге бирелә бүген. Районның барлык хуҗлыкларыннан да 360 савымчы «Киекле» крестьян кооперативлары берлегенә традицион слетларына җыйналалар. Әмма, традицион булса да, савучылар җыенының быелгысы бик күпләр өчен аеруча истәлекле буласы. Ник дигәндә, быел районның барлык хуҗалыклары савучылары да слетка узган елгыдан бик күпкә күркәмрәк эш нәтиҗәләре, соңгы еллар өчен гадәттән тыш саналырдай рекордлы күрсәткечләр белән киләләр.

(Ахыры 2нче биттә)

## УҢГАН КЫЗЛАР, ФЕРМА КЫЗЛАРЫ





Язмышларын даимилек, түземлелек сорый торган авыр терлекчелек эшенә багышлаган хатын-кызларның һәммәсе аерата хөрмәткә, олылауга лаеклар. Иртәнге таңнан төнгәчә аяк өстендә алар: малларны карау, савудан тыш хатын-кызга үз хуҗалыгында да күпме йорт мәшәкатьләре тартырга, гаилә учагын сакларга, балалар үстерергә кирәк бит әле.

Ирина Владимировна Михеева шушы олы тормышта ышанычлы тәүге адымнарын ясарга өлгергән савучы инде: терлекчелектә эшләү тәҗрибәсе, уңган дигән даны бар, ике ел рәттән район савучылар конкурсында җиңүче исемен яуларга өлгерде. Әле күптән түгел генә район данын яклап республика саву осталары конкурсында катнашты. Шуның өстәвенә, матур башланып киткән гаилә тормышы, күбәләктәй сөйкемле булып үсеп килүче нәни кызчыгы бар. Тормыш түгәрәк, бәхет бөтен булсын өчен тагы ни кирәк.

«Чирмешән» КХАсының яшь савучысы Илһамия Хәсәнҗанованың исә әле терлекче язмышы башланып кына килә. Авырлыгын күрә торып, әнисе Миннеруй апа һөнәрен сайлады ул. Беренче адымнары өметле аның: район конкурсында катнашкан яшь савучылар арасында Илһамия I урынны яулады. Шикләнмибез: тырыш кызга уңышлар да, бәхет тә килер. Без аңа шуны телибез.

**Рәсемнәрдә: И.В.Михеева, район авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсе начальнигы Р.М.Гыйбадуллин И.Хәсәнҗановага җиңүче тасмасы бәйли. Н.КВАШНИНА фотолары.**

## Һәркемнең үз акчасы

Республикада әйләнештә йөргән «Ак Барс» банкы вексельләренә хуҗалык җитәкчеләре дә, эшмәкәрләр дә бераз шикләнеп карыйлар. Чөнки «бу кыйммәтле кәгазьләрнең көннәре санаулы» дигән сүзләр йөри. Шуңа күрә дә күпләр алардан котылып калырга тырыша. Бу гамәл исә, үз чиратында, вексельләргә дисконтны да арттыра.

Вексельләргә мөнәсәбәт республикада бик сак булса да, Казан шәһәре хакимиятенең дә үз вексельләрен чыгарырга ниятләве мәгълүм булды. Төгәлрәк итеп әйткәндә, шәһәр хакимияте «Татфондбанк» акционерлык инвестиция коммерция банкыннан ун миллиард сумлык вексельләр сатып алу турында килешү төзегән.

Шәһәр хакимияте әлеге вексельләр белән бюджет оешмаларын, сәүдә сферасын һәм предприятиеләрне финансларга уйлый.

## БЕР САН БЕЛӘН ГЕНӘ ДИМӘГӘН

### «Уңыш - 97» матбугат үзәге хәбәр итә

*Коры печән запасы аз - азлап кына булса да артуга барса да ( бүген хуҗалыкларда 19 мең тоннага якын печән запасы бар инде), хәзер терлек азыгы хәзерләүчеләрнең бар тырышлыгы сенаж салуга юнәлгән. Кичәге көнгә район буенча берьеллык үләннәр 2 мең гектар мәйданда чабылып, базларга тутырылган сенаж запасы 13 мең тонна чамасы булды. Хуҗалыкларның абсолют күпчелегендә сенаж салу агрегатлары ярыйсы гына эшләп торсалар да, сан артыннан куып эшнең сыйфатын күз уңыннан читкә җибәрергә ярамавын да искәртергә туры килә. Сүз беренче чиратта базларга тутырыла торган массаның дымлылыгы сенаж салу технологиясе таләпләренә җавап бирелек булу турында кайгырту хакында бара. Кызганычка каршы, кайбер урыннарда чабылган массаны тиешенчә җилләтмичә торып базга тутыру очраклары бар. Ә сенаж яхшы саклансын, әчелеге нормадан артык булмасын өчен чабылган массаны дымлылыгы 35 процентттан да артмаслык итеп кипшенгәч кенә урнаштыру шарт. Бу эшне контрольдә тотучы «Агрохимсервис» АҖ лабораториясе мәгълүматларына да колак салырга кирәк. Хуҗалыкларның ззоветбелгечләренә бу чорда сенаж базлары тирәсендә әледән - әле булып тору мөһим.*

*Бер үк вакытта күпьеллык үлән участокларын минераль ашламалар белән тукландыру, чиста парга калдырылган җирләрне эшкәртү кебек мөһим эшләрне дя чиратка куярга ярамый.*

## УРАККА ЕРАК КАЛМЫЙ

Сарылыгы көннән - көн арта барган уҗым басулары уракка санаулы гына көннәр калып баруын искәртәләр. Пәнҗешәмбе көнне Сарман районында узган республика зона семинар - киңәшмәсе дә шушы зур сынауны уңышлы узуга әзерлек мәсьәләләренә багышланды. Анда безнең районнан да авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсе, «Сельхозтехника» һәм «Агрохимсервис» акционерлык җәмгыятьләре башлыклары катнашты. Семинар - киңәшмәдә катнашучылар районның күп кенә хуҗалыкларында булып быелгы уракны уздыру технологиясе, ел үзенчәлекләреннән чыгып кулланылачак һәртөрле техника белән таныштылар, ындыр табаклары һәм техник хезмәт күрсәтү пунктларының урак чорына ничек әзерләнүен карадылар. Семинарда бөртекле һәм бөртекле - кузаклы культураларны урып - җыю белән берләттән, саламны эш итү, уңышы җыеп алынган мәйданнарны эшкәртү, тунга сөрү үзенчәлекләре турында да сөйләп тә аңлатылды, гамәли рәвештә дә күрсәтелде.

Семинар - киңәшмәдә бер үк вакытта терлек азыгы хәзерләү, күпьеллык үләннәрнең орлыкка үстерелә торган мәйданнарын карау мәсьәләләре турында да зур сүз булды, терлекчелек мәсьәләләре дә игътибар үзәгеннән читтә калмады.

Республика семинар - киңәшмәсендә билгеләнгән барлык бу юнәлешләр буенча да районыбызда җитди эш алып барыла инде һәм язын иртәрәк аяк киенгән игенчеләребезгә, бөртекнең тулысынча өлгерүен көткән тәкъдирдә дә уракка башкалардан иртәрәк керешергә туры киләчәк. Шуңа күрә бүген һәр хуҗалыкта уракка әзерлек мәсьәләсе һәрдаим игътибар үзәгендә булырга тиеш.

## Юл салына

Яңа төзелеп килә торган Карл Маркс проспектында яшәүчеләр өчен явымлы көннәр «юлсызлык» сүзенә тиңдәш булып килделәр. Күптән түгел үзләренә атап салынган йортка күчеп килгән инвалидлар, сугыш ветераннарының да яңа фатирларына «әләгә» алмыйча изаланган чаклары еш булды. Норлат җирле үзидарә Советы карары буенча әлеге микрорайонны төзекләндерү вазифасы «53 нче СМУ» чикләнгән җаваплылыктагы җәмгыятькә йөкләнде. Финанс һәм икътисадый кыенлыкларга чумган предприятие бу вазифаны намус эше итеп кабул итте һәм менә күптән түгел микрорайонда юл салу турында ДРСУ белән килешү төзеде. Бүгенге көндә алар тарифыннан 581 квадрат метр мәйдан вак таш белән түшәлде. Предприятие микрорайон юлларын төзекләндерүне дәвам итәргә ниятли.

# Бүген - савымчылар җыены

(Ахыры. Башы беренче биттә).

Районның яңа җитәкчелеге терлекчелектә хәлне тамырдан яхшырту буенча күргән зур колачлы оештыру чаралары,аерым алганда малларны карау һәм ашатуны технология таләпләренә туры китереп алып баруга ирешү, ферма эшчәннәренең хезмәтенә түләү мәсьәләләрен игътибар үзәгенә алуы, аларның хезмәт шартларын җиңеләйтүгә юнәлдерелгән курс тоту нәтиҗәсе буларак, район буенча быелның алты аенда бер сыердан уртача савым узган елгыдан 509 килограммга күбрәк булды, дәүләткә сөт сатуның яртыеллык планы 163 процентка үтәлде.

Планның шулай уңышлы гамәлгә ашырылуына хәзерләүләр пунктына 10 - 11 мең центнер продукция тапшырган Мичурин исемендәге, Хафизов исемендәге, Синдряков исемендәге, яртыеллык планны икеләтә диярлек һәм аннан да күбрәккә арттырып үтәгән «Кондырча», «Рассвет» «Татарстан», «Якты Күл» хуҗалыклары, сөт хәзерләүне узган елгы дәрәҗәдән ике тапкыр диярлек һәм аннан да күбрәккә арттырган шикәр заводы, «Агрохимсервис» ярдәмче хуҗалыклары, «Алга», Киекле» һәм башка хуҗалыклар аеруча зур өлеш керттеләр. «Дуслык» ярдәмче хуҗалыгында, «Кондырча»да алты айда бер сыердан уртача 3392 - 3583 килограмм сөт савып алдылар, Мичурин исемендәге, «Якты Күл»,- «Рассвет» хуҗалыкларында, «Агрохимсервис»ның ярдәмче хуҗалыгында малларның продуктлылыгы 2 мең килограмм һәм аннан да артыграк булды.

Бүгенге җыенда сөт җитештерү һәм хәзерләүдә зур казанышларга ирешкән бу хуҗалыкларның җитәкчеләре һәм терлекчелек буенча баш белгечләре дә телгә алыначак, бу тармакта эшләрнең кискен яхшыруына зур этәргеч биргән алшартлар һәм бүген алда торган бурычлар һәм проблемалар турында да сүз булачак. Шулай да хөрмәтнең иң олысы, сүзләрнең иң җылылары, бүләкләрнең иң затлылары сөт муллыгы өчен көрәштә тырыш хезмәтләре белән турыдан - туры катнашучы, олы хөрмәткә лаек фидакарь савымчыларыбызга адресланачак. Аларның һәммәсенең фидакарьлеге алдында баш иярлек. Авыр да,мәшәкатьле дә савучы хезмәтен гомерлек һөнәр иткән өлкән терлекчеләребезнең түземлегенә һәм чыдамлылыгына ничек сокланмыйсың. Әнә «Рассвет» хуҗалыгыннан Фәүзия Хәмитгата кызы Сатдарова инде 43 ел шушы эштә. Аның хезмәттәше Фәһимә Мингали кызы Сатдарова, «Заря»дан Людмила Федоровна Казакова, Валентина Тимофевна Морозова, шикәр заводы ярдәмче хуҗалыгыннан Зинаида Семеновна Алексеева, Галина Николаевна Будяшкина гомерләренең өчәр дистә елдан күбрәген шушы хезмәткә багышлаганнар. «Норлатнефтепродукт» һәм шикәр заводы ярдәмче хуҗалыкларыннан Раиса Яковлевна Белова,Зинаида Васильевна Порфирьева, «Рассвет»тан Фәүзия Касыйм кызы Әхмәдиева, «Родина»дан Людмила Федоровна Васильева, Агреппина Ивановна Илюхина һәм башка бик күпләрнең чирек гасырдан күбрәк гомере терлекчелектә үткән. Терлекчелек ветераннарыбызның шактые бүген дә район савучылары ярышының алгы сафында атлыйлар. «Кондырча»дан Минсара Вәлиулла кызы Бакирова, Галия Усман кызы Әбделманова, Саимә Вәлиәхмәт кызы Ибәтуллина һәм башкалар, Мичурин исемендәге хуҗалыктан Валентина Васильевна Тимофеева, «Дуслык»тан Мәрьям Шәриф кызы Гыймадиева, шулай ук исемнәре алдарак телгә алынган ветераннарның да күпләре, тагын дистәләгән савучы яртыеллыкны үз карамакларындагы сыерлардан уртача 3 мең килограмм һәм аннан да күбрәк продукция алып тәгәлләделәр. Бүген аларның узган кышлату чоры нәтиҗәләре буенча иң алдынгылары махсус билгеләп үтеләчәк. Уңганнарның да уңганнары арасында савучы булып әле берничә генә ел эшләүче яшьләрнең дә булуы куандыра. Мичурин исемендәге хуҗалыктан Татьяна Ермуллина, «Дуслык»тан Галия Сатдарова, «Конлырча»дан Зилә Усманова һәм башка бик күп яшь савымчылар өлкән хезмәттәшләре янәшәсендә зур горурлык белән утырачаклар бүген. Һәм савучылар отрядына яшьләр өстәлеп, аларның ветераннарга тиңләшердәй хезмәт нәтиҗәләренә ирешүләре терлекчелек тармагының киләчәге дә өметле булуына ышанычны ныгыта.

Җыенда тармакта эшне алга таба да тотрыклы төстә яхшырта бару юллары турында да сүз булачак дидек. Бүген район буенча бер сыердан уртача 13 килограммнан артык сөт савылып, Мичурин исемендәге,»Дуслык», «Кондырча» хуҗалыкларында ул күрсәткеч 20 - 24 килограмм, «Рассвет»,»Якты Күл», «1 нче Май»хуҗалыкларында, «Агрохимсервис»ның ярдәмче хуҗалыгында 15' килограмм һәм аннан да артыграк булса да, продуктлылыкның тотрыклылыгына ирешү мөмкинлекләре һәркайда да тулысынча файдаланылмый әле. Һәм бүгенге җыен бу тармакта алынган курсны нык тоту, районыбыз терлекчеләренең сөт җитештерүдә республика күләмендә яуланган үрләрендә ныграк торуына ирешү юллары турында эшлекле фикерләшү булачак. Слеттагы күтәренкелек, күңел көрлеге сөт муллыгы хакына киеренке көрәштәге терлекчеләрне алга таба да бүгенгедәй яхшы эшләргә рухландырыр дип ышанабыз.



## КУЛЛАРДА КӨЧ КҮП ӘЛЕ

Минсара апа ферма белән өе арасындагы юлны авыл мәктәбен тәмамлап чыкканны бирле таптый. Үзе җитез, үзе уңган. Күбекле җылы сөтләрен биреп торган малларын олыларча йомшаклык белән иркәләп, яратып карый. Кыскасы, яшьтән үк күңеле эшенә ятты. Нәтиҗәдә күңел биреп, тырышып башкарган хезмәт уңышсыз да булмады: күрсәткечләре әйбәт иде, район сыер савучылары конкусларында призлы урыннар яулады, хәтта республика күләмендә дә үзен күрсәтә алды. Мәсәлән, 1971 елда Зеленодольскида республика сыер савучылары конкурсында беренчелекне яулап, районына зур дан китерде. Хәер, бер эш белән генә дә мәшгуль булмады ул: авылын яшәртү, агарту теләгеме, кызыклы, баерак рухи тормышта яшәүгә омтылышмы аны җәмәгать эшләрендә дә актив катнашырга мәҗбүр итте. Нәкъ шул сәбәпледер инде халык аны авыл Советына да, район Советына да депутат итеп сайлаган еллары булды.

Хәзер фермага килгәненә 32 ел тулганның сизелмичә дә калуына хәйран була. Ире Минияр белән аңлашып, бер - берсен хөрмәт итеп 25 ел яшәделәр, 4 бала тәрбияләп үстерделәр, балаларын да хезмәт сөючән итеп тәрбияләргә тырыштылар.

- Әни өйдә һәрвакыт сыерларын сөйли. Алар белән эшләү генә түгел, алар хакында сөйләүдән дә тәм табадыр, мөгаен. Сөтне күп биргәндә аның кәефе тагын да яктырып китә, «кайберләреннән 26шар литр савам»- дип шатланып хәбәр итә,- дип сөйли әнисе турында «Кондырча» күмәк хуҗалыгында бухгалтер булып эшләүче олы кызы Миләүшә.

Быел Минсара апа таналар группасын карый. Ярты елга һәр сыер башыннан савылган сөте 4000 килограммнан артып китә. Күптән түгел район сыер савучылары конкурсында икенче урынны алып, төсле телевизор белән бүләкләнде һәм шуның белән гаилә бюджетына да саллы ярдәм китерде. Әле менә үзләре хөрмәтенә оештырылган слетны да зарыгып көтә. Яшьлектәгедәй актив җанлы, җитез гәүдәле Минсара Бакирова бу шатлыклы вакыйгадан читтә калamы соң?

Н.КВАШНИНА фотосы.

Авыл хәбәрләре

## Теләп катнашалар

Җәйге чорда авыл халкының кунагы - мәшәкате бер дә бетеп тормый, хуҗалыгында да төп ризык сөт - катык, каймак була. Шулай да хәзер байтак хуҗалыклар икешәр сыер тотканлыктан, авыл кешесе артып калган продукциясен дәүләткә тапшыру җаен таба. Ни дисәң дә, акчасы да кирәк бит әле аның! Ә сөт тапшырган өчен исәп - хисап, мәгълүм булганча, шунда ук ясала.

Иске Әлмәт җирле үзидарә Советы территориясендә яшәүчеләрнең быел шәхси хуҗалыкларыннан продукция тапшыруда активлыклары шуның белән аңлатыла да. Быел без 61316 кг. сөт сатып, яртыеллык планны уңышлы гамәлгә ашырдык. Иске Әлмәт авылыннан халыктан сөт җыючыбыз Марс Ибраһимович Баһаветдиновның өлеше аерата саллы керде бу күрсәткечкә. Ул соңгы май, июнь айларында гына да 5692, 7046 кг. продукция җыеп озатты. Ә иң актив сөт тапшыручылардан Рәис Насыйбуллин, Тәнзилә Касыймова, Нажия Гайсина исемнәрен атар идек. Алар елның - елында дәүләткә сөт сатуда теләп катнашалар.

М.ХӘМИДУЛЛИНА.
Иске Әлмә[т] авылы.

## Азыксыз калмабыз

«Родина» КХАсы елның-елында кышкы чорга мул азык белән керә. Быел да Владимир Иванович Илюхин җитәкчелегендәге азык әзерләү звеносы бу җәһәттән тырыш хезмәт куйды. Звено тырышлыгы нәтиҗәсендә 400 тонна печән эскертләнде. Хәзер төп көч сенаж салуга юнәлтелгән. Берочтан витаминлы үлән оны җитештерүгә дә игътибар кимеми. Оператор Юрий Аркадьевич Питимиров бу файдалы азыкны күпләп әзерләү өчен шулай ук көчен кызганмый.

П.ИЛЮХИН.

# Инвалидларга - яңа льготалар

(Татар - Информ). Элемтә хезмәте, торакны ведомстводан тыш саклау, күмәк антенна, ягулык китергән өчен транспорт хезмәте күрсәтүгә түләүдә льготалардан файдаланучы кешеләр исемлеге киңәйтелде. Бу хакта Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының быел 9 июльдә чыккан карары бар.

Хәзер инвалидлар (әбүген алар республикада 186999 кеше) телефон һәм радиодан файдаланган өчен яртылаш кына түләячәкләр. Моның өчен район (шәһәр) халыкны социаль яклау бүлегенә инвалидлык турында дәүләт медицина - социаль экспертиза хезмәте учреждениеләре яки ВТЭК тарафыннан бирелгән белешмә китерергә кирәк. Радио өчен абонент түләвенә льготаны ЖЭУлар (ЖКОлар) рәсмиләштерә.

Социалистик Хезмәт Геройларына һәм Хезмәт Даны орденының тулы кавалерларына мәгълүм льготалар беркетелгән. Шушы категориягә керүче 112 татарстанлы һәм аларның гаилә әгъзалары телефон өчен һәм ведомстводан тыш сак сигналыннан файдаланган өчен түләүдән (торак фондының төренә бәйсез рәвештә) тулысынча азат ителәләр. Хәзер алар өйләренә телефонны чиратсыз кертә һәм торакны ведомстводан тыш сак сигналы чаралары белән җиһазлый алалар. Әгәр Социалистик Хезмәт Геройлары һәм Хезмәт Даны орденының тулы кавалерлары яши торган йортлар үзәктән җылытулы булмаса, аларга ягулык бушлай бирелә.

**Сәүдә һәм санитария - гигиена**

# Капкан ризыгың бозылмаганмы?

Районда РФнең «Халыкның санитария - эпидемиология иминлеге турында»гы һәм «Кулланучылар хокукларын яклау турында»гы Законнары нигезендә безнең районда байтак эш башкарыла. Мәсәлән, ваклап сату объектларын санитар тикшерү буенча гына да беренче яртыеллыкта 50гә якын рейд үткәрелде. Нәтиҗәдә 70ләп ваклап сату белән шөгыльләнүчегә 2165 мең сум күләмендә штраф салынды. Штрафлар күбесенчә тиешле булмаган урында сәүдә иткән өчен салынды. Шулай ук үзвакытында медицина тикшерүе үтмәгән, сәүдә кагыйдәләрен бозган сатучылар да административ җаваплылыкка тартылды.

Шунысын әйтергә кирәк, шәһәр сәүдә объектларында әлегә элементлар санитар - гигиена таләпләре дә, ит - сөт товарларын тиешле кагыйдәләр буенча сату да тулысынча үтәлми. Шулай, сәүдә кагыйдәләрен бозучы эшмәкәрләр Козлова, Захарованы лицензияләреннән мәхрүм итү турында сүз кузгатылды. Районның төрле почмакларында азык - төлек продуктлары белән сәүдә итү фактлары тыелды. Норлат шәһәре һәм Киекле авылында сезонлы һәм стационар базарлар булдыру максатында урыннар билгеләнде. Санитар кагыйдәләргә нигезләнеп азык - төлек продуктлары белән сәүдә итү промышленность һәм хуҗалык товарларын сатудан аерылды.

Бүгенге көндә лицензия алу өчен гигиеник белешмә бары тик тулы медицина тикшерүеннән соң, яңа медицина кенәгәсе алгач, азык - төлекне саклау һәм реализацияләү урыннарын санитар тикшерүдән соң гына бирелә.

Эчәк инфекцияләрен һәм азык - төлек белән агулану очракларын кисәтү максатында ТР дәүләт баш санитар табибы тарафыннан «Җәйге чорда азык - төлек товарларын ваклап сатуны тәртипкә салу буенча чаралар турында» карар кабул ителде. Ул июнь аеннан октябрьгәчә гамәлдә булачак. Карарда тиз бозыла торган азык - төлек чималын, шул исәптән вакуум упаковкадагыларын да эш урынында суыткыч булмаса, ачык һавада сату тыела. Он, шикәр комы кебек азык - төлек чималларын да төрелмәгән килеш сатарга рөхсәт ителми. Пастеризацияләнгән сөтне изотермик сыешлыксыз булмыйча урамда сатарга, шул исәптән аны куллану алдыннан кайнатырга кирәклеге турында искәртүче аншлагсыз сатарга ярамый. Ит, балык консервлары, үсемлек маен, майонез, йомырка, шоколад һәм башка чит ил кондитер товарларын да температура 20 градустан артканда ачык сәүдә мәйданында сату тыела.

Сәүдә, җәмәгать туклануы предприятиеләре, чикләнгән җаваплылыктагы җәмгыятьләр һәм ширкәтләр җитәкчеләре, шәхси эшмәкәрләр ваклап сәүдә итү урыннарында санэпидкүзәтү үзәгеннән сәүдә итүгә рөхсәт алырга һәм шулай ук сатыла торган продуктлар асортименты хакында килешергә тиешләр. Сатучыларда медицина кенәгәсе һәм күкрәктә фирма билгесен булдыру да таләп ителә.

Сатып алучыларга мөрәҗәгать итеп шуны искәртеп үтәсе килә: үзегезгә кирәкле продуктларны сатып алганчы сатучыдан гигиеник сертификат сорагыз, тәкъдим ителгән товарларның саклану срогына, саклану шартларына игътибар итегез һәм шулай ук чит ил продукларын куллану турында аңлатманың русча тәрҗемәсен таләп итегез. Шуны истә тотыгыз: сезнең сәламәтлегегез куллана торган ризыгыгызга бәйле.

**Л.КАРМАЛЬСКАЯ,**
**район санэпидкүзәтү үзәгенең туклану гигиенасы буенча табибы.**

## *КОТЛЫЙБЫЗ!*



*Зирекле авылында яшәүче **әтиебез Касыйм Вәли улы Һадиевка** 20 июльдә 60 яшь тула. Без аны юбилее белән чын күңелдән котлыйбыз. Аңа озын гомер, тыныч тормыш телибез.*

*Котлы булсын, әти, туган көнең,*
*60 яшь тулган көнең.*
*Безнең өчен һәрчакта да*
*Изге булды күңелең.*

***Иң изге теләкләр белән кызың, киявең, улың, киленең, оныкларың.***

Түбән Норлат авылында яшәүче кадерле **әниебез Сания Мингата кызы һәм кадерле әтиебез Хәмзә Фәттах улы Хөсәеновларның** бергә тормыш итүләренә 20 июльдә 50 ел тула. Аларны алтын туйлары белән чын күңелдән котлыйбыз, саулык - сәламәтлек, тигез һәм озын гомер телибез.



**Улы Фоат, килене Флюра һәм оныклары.**

## *КОТЛЫЙБЫЗ!*

*Иң кадерле кешебез, өебезнең нуры, тормышыбызның кояшы **Зөлфия Мифтах кызы Вәлиеваны** 50 яшьлек юбилее белән чын күңелдән котлыйбыз. Сабырлыгы, тыйнаклыгы, киң күңеле, уңганлыгы өчен без аны чиксез яратабыз, гомергә сау - сәламәт булып, бүгенгедәй килешеп - аңлашып, бергә - бергә бәхетле яшәргә язсын иде дип телибез.*



***Олы ихтирам белән - ире Надир, улы Илшат, кызы Люция, кияве Илнар, оныгы Ләйлә.***

## БЕРӘҮЛӘР - ТӨЗИ, ИКЕНЧЕЛӘРЕ - КӨТЕП ЙӨРИ

Салдакай мәчетендә кинәттән чыккан янгын авыл мөселманнары арасында күп аңлашылмаучылык, низаглар кузгатты. Инде мәчет авырлык белән генә торгызылып килә, әмма аны төзүдә янә бердәмлек, киңәшеп эшләү җитмәү үзен сиздереп тора. Өлкәннәр арасындагы бу таркаулык турында мәчет төзелешендә актив катнашучыларның берсе **Гаяз ага Нуретдинов** безгә бер язган иде инде. Дин йортын тизрәк төгәлләү җәһәтеннән аның якташларына тагы сүзе бар.

***

Мәчетебезнең ниһаять, түбәсен яптык, әмма башкарасы эчке эшләре байтак әле. Финанс кытлыгы гел генә чабудан тартып тора. Дөрес, сәдака бирүчеләр аз түгел. Морзаханов Хәбибрахман, Шәйдуллина Руфия, Зәйнетдинов Касыйм бабайлар үз хәләл акчаларын төзелешкә керттеләр, күршеләребез Кәкре Атау мәчетеннән дә 500 мең сум акча бирделәр. Тик чыгымнар зур - зур бәяне таләп итә шул! Шуңа да авылыбызга янәдән иман нуры бөркиячәк мәчетебез сафка бассын дисәк, хәлдән килгәнчә ярдәм күрсәтик, җәмәгать. Бу максатларга сәдакагызны Минвәгыйзь Мортазинга тапшыруыгызны сорар идек, чөнки төзелеш эшләрендә ул башлап йөри бит.

## Тавык куйган рекордлар



***Гиннесның Рекордлар китабына кергән тавыклар тормышыннан кызыклы берничә мисал.***

* Белгәнебезчә, тавыклар оча алмый. Ә менә Чемпион кушаматлы тавык 1981 елда 95 метр араны очып барган. 8 март көнне...

* Дөньяда иң эре тавык - брахма токымлы. Аның уртача авырлыгы 5 килограмм.

* 1956 елда Бланш исемле тавык ике сарылы һәм ике катлы кабыклы күкәй сала.

* 1936 елда Блэк кушаматлы тавык 31 см. биеклектәге, 23 см. киңлектәге күкәй салган.

* Америкалы Эрнст Хансен бер тавыкны 3,5 секунд эчендә йолкып бетереп, рекорд куйган.

* Венгриядә сенсацион вакыйга була - бер тавык әтәчкә әйләнә. Бу тавык 11 ел буе күкәй сала - сала да, аннары әкренләп көннән - көн әтәч кыяфәте ала, аның кебек кычкыра башлый.

* Тавык борын - борыннан надан кош булып исәпләнә. Ләкин Бөекбритания биологы Катрина Райа раславынча, аларны һич тә надан дип әйтеп булмый. Бер төркем чебигә берничә мәртәбә башта «дусларының», аннары аларга таныш булмаган чебиләрнең фотоларын күрсәтәләр. Һәр очракта да чебиләр «дуслары» рәсеменә генә җанланалар.

* Һавада агулы матдәләр булса, тавыклар беренчеләрдән булып сигнал бирә. Америкалылар аларны үзләре белән Кувейтка алып баргач, тавыклар сугыш һөҗүме вакытында хәвеф сигналы бирәләр.

* Германиянең авыл хуҗалыгы министрлыгы экспертлары тавык, каз, үрдәк һәм башка йорт кошларының тагын бер яңа файдалы сыйфатын ачалар. Алар әйтүенчә, бу кошлар янында булганда кешенең нервлары тынычлана.

* Парижның бер бай ресторанында тавыкның сул аягыннан пешерелгән ризык уң аяктан пешерелгән ризыктан кыйммәтрәк тора. Менюга өстәп болай дип тә язылган: «Тавык уң аягына басып йоклый, шуңа күрә аның сул аягы йомшаграк һәм тәмлерәк».


## Белдерүләр



### Сатабыз

**ВАЗ - 2106га яңа двигатель**. Тел.: 5 - 23 - 25.

***

**Тимер юлчылар поселогында барлык уңайлыклары булган бер бүлмәле фатир**. Арадашчы телефоны: 65 - 3 - 17, Нефтьчеләр коммутаторы аша.

***

**ВАЗ - 2106**. Тел.: 5 - 14 - 36.

***

**Ашыгыч рәвештә ВАЗ - 2106.** Советская ур., 187 - 26 адресына 18 сәг.тән соң мөрәҗәгать итәргә.

***

**1993 нче елгы САЗ - 3511 үзбушаткычы, бәясе 14 млн. сум.** Тел.: 2 - 25 - 15.

***

**1986 елгы ВАЗ - 2121 «Нива».** Тел.: 2 - 17 - 19, 5 - 24 - 50 (18.00 сәг.тән соң).

***

***Россиядә һәм чит илдә җитештерелгән йорт җиһазларына заявкалар кабул ителә. Һәрвакыт сатуда стенкалар, йомшак мебель, кухня һәм йокы бүлмәсе гарнитурлары, диван - кроватьлар, прихожаялар, шкафлар, кухня почмаклары бар.*** Адрес: Куйбышев ур., 29 - 5.

**Бәясе 25 мең сумнан 50 кг.лы цемент, 220 меңнән 50 кг.лы шикәр комы, 145 мең сумнан 50 кг.лы югары сортлы он, «Дружба» бензопычкысы (900мең сум). Китереп бирәбез**. Адрес: Строительная ур., 27 - 1. Лицензия А 96, № 118798.

**Кв. метры 32 мең сумнан цинкланган, 45 мең сумнан буялган (коррилда, рубин, диңгез дулкыны төсләре) калайга заявкалар кабул итәбез**. «Саламат» кибетенә мөрәҗәгать итәргә. Заявка 10 көн эчендә үтәлә, түләү товарны алганда. Лицензия А - 96 № 076058.

### Төрлесеннән

**Теләсә күпме күләмдә шунда ук исәп - хисап ясау юлы белән дизель ягулыгы, шикәр комы, коры сөт, югары сортлы он, дуңгыз һәм сыер итләре сатып алам. Алмашка КамАЗ машинасына һәм тракторларга запас частьләр, КамАЗга һәм авыл хуҗалыгы техникасына резиналар тәкъдим итә алам.** Тел.: Яр Чаллыда (8552) 53 - 13 - 18, Игорь.

***

**Хаҗетдинова Л.И. исеменә документлар белән сумка табучыны бүләк бәрабәренә кайтарып бирүен сорыйбыз.** Тел.: 5 - 25 - 44.

***

**Шәһәрара телефон пункты бинасында «Татнефть» АҖе акцияләрен сатып алабыз. Эш вакыты 21 нче июльдән башлап 10 сәг.тән 19 сәг.кә кадәр. Лицензия № 3013.**



БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2306 данә.